# МӘКТӘП ДУЛКЫНЫНДА

***Куәм урта гомуми белем мәктәбе газетасы*** *№3 Январь 2023 ел*

## *Укучыларыбыз иҗаты*

### Казан шәһәре буйлап сәяхәт



Без, 10 нчы сыйныф укучылары, 17 нче декабрь көнне Казан каласына сәяхәткә юл алдык. Сәяхәтебезне Кремльдан башлап җибәрдек. Кремль Казанның нәкъ үзәгендә урнашкан. Кремльга кергән юлда ап-ак Спас манарасы балкып тора. Шулай ук Кремль янында герой шагыйрь Муса Җәлилгә атап куелган һәйкәлне дә күрдек. Казан шәһәрен һич тә Сөембикә манарасыннан башка күз алдына китереп булмый. Кол Шәриф мәчетен тышкы яктан гына түгел, хәтта эченә үтеп кереп карау бәхетенә ирештек. Азан тавышын тынлагач,йөрәкләребездә ниндидер җылылык һәм җинеллек сиздек. Ул искиткеч матур һәм зур мәчет икән. Кремль безгә бик ошады. Кремль янында истәлеккә фотолар ясагач, Бауман урамына юл тоттык. Андагы матурлыкка сокланып таң калдык. Туган Авылым комплексына кермичә узып китү дә мөмкин түгел иде. Кичләтеп, Габдулла Кариев исемендәге Татар дәүләт яшь тамашачы театрына кузгалдык. Туфан Миңнуллинның "Супер кияү" исемле комедиясен карадык. Комедия булуына карамастан, ул бик эчтәлекле, мәгънәле спектакль булды. Казан буенча экскурсия безгә бик ошады. Әлеге сәяхәтне оештырган өчен сыйныф җитәкчебез Айсылу Рафиз кызына зур рәхмәт!

*Зәлия Гараева, 10 сыйныф*

### Әкият сөйлим сезгә

### Йозак һәм ачкыч.

Борын – борын заманда патшаның бер йозагы булган.Әмма аның ачкычы булмаган.Ул һәрчак бикләнеп кенә тора ди. Бер көнне патша шундый карар чыгарган:

-Кем дә,кем шушы йозакны ачар өчен бер ачкыч таба,шуңа ярты байлыгымны бирәм,-дигән. Бик күп җирләрдән ачкычлар алып килгәннәр, әмма йозакны ача алмаганнар.

Күрше авылда оста тимерче яшәгән.Ул йозакны килеп караган да икенче көнгә ачкыч ясап алып килгән һәм йозакны ачкан. Патша бик куанган һәм үзенең вәгъдәсендә торган.

Үзенең тырышлыгы аркасында тимерче бай яши башлаган.

*Газизов Сәйдәш, 7 сыйныф*

### Абыем белән горурланам.

Нинди кеше батыр була, дип сорасалар, һичшиксез, минем абыем дияр идем. Минем туганнан туган абыем Ильяс - минем иң якын кешем. Ул бик батыр йөрәкле, кешелекле.

Ул, Вахитов Ильяс Мәхмүт улы, 1980 елның 24 нче августында дөньяга килә. Әтнә районы Әйшияз авылында яши.1987 нче елда Әйшияз башлангыч мәктәбенә укырга керә. Анда өченче классны тәмамлаганнан соң, 1991нче елда Куәм урта мәктәбендә укый башлый. Тугызынчы сыйныфны тәмамланач, Әтнәдә укуын дәвам итә. Анда тракторист машинист һөнәрен үзләштерә. 1999 нчы елның ноябрендә армия сафларына алына. 6 ай Североморскийда укуда була. Анда янгын сүндерү һөнәре буенча белем ала. Аннан соң Авианесущий крейсер “Адмирал Флота Советского Союза Кузнецов”ка кучерелә. Ул корабльдә ике ел буе диңгезче булып хезмәт итә. Анда төрле куркынычсызлыклар булмасын өчен зур тырышлык куя. 2001нче елда туган ягына әйләнеп кайта. Кайткач, бераз колхозда эшләп ала. 2013 нче елда Әтнә районының янгын сүндерү бүлегендә эшли башлый. Армиядә алган белемнәре бу һөнәрне башкарырга ярдәм итә. Бу бик җаваплы ,авыр, игелекле һөнәр. Төрле авыр ситуацияләр белән очрашырга туры килә, ди абыем. Бу эштә бик җитез, зирәк, кыю булырга кирәк. Кечкенә генә төгәлсезлек тә зур фаҗига тудырырга мөмкин. Ильяс абый уз эшен бик яратып башкара. Мин абыем белән горурланам. Хәвеф-хәтәрләр булмасын, исән-сау эшләсеннәр дигән теләктә калам!

*Шакирова Айзилә, 9 сыйныф*

### Сузем әбием турында!



Минем әбием Шигапова Зәлфирә Шәрифулла кызы 1953 елнын 4 июлендә гади колхозчы гаиләсендә дөньяга килә. Ул башта Дусым башлангыч мәктәбендә, Куәм сигезеллык мәктәбендә һәм Кунгәр урта мәктәбендә белем алган. Шуннан сон ул Куәм мәктәбенә пионервожатый, педагог – оештыручы, музыка укытучысы, сыйныф житәкчесе булып эшләгән. Кайчандыр «кызыл галстуклы пионер хәрәкәтенең гөрләп торган чорлары бар иде» дип искә ала ул яшь чакларын. Төрле кызыклы кичәләр, очрашулар уткәргәннәр, файдалы эшләр башкарганнар . Эш дәверендә кызыклы вакыйгалар да, гыйбрәтле хәлләр дә күп булгандыр. Анын күңеленә иң сеңеп калганы: Кенәр интернат мәктәпкә бару булган. «Шәфкатьлелек» акциясе белән беренче тапкыр яңа ел күчтәнәчләре җыеп интернатка бару. Безне ишек төбендә үк ятим балалар каршы алды, өс баш бөтен күренсә дә эни кулы, эни назы тимәгәне күренеп тора. Интернатның эченә уткәч балалар безне сырып алдылар. Янынма жыелган балаларны күреп минем жаным тетрәнде, берсенең аркасыннан сөям, икенчесен назлап башыннан сыйпыйм, өченчесенен кулына конфет сузам, ә үземнен күземдә мөлдерәмә яшь. Кечкенә генә бер татар малаен баштан аяк киендереп чыгардым һәм юл буе «күргәннәргә сабырлык бир» дип теләп кайттым. Кенәрдән кайткач класска кереп : «Эти – эниләрегезнең кадерен белегез, балалар!» дип, әңгәмәләр уткәрдем. Күргәннәремне башкаларга җиткерергә теләдем. Бала күңеле ул иң сизгер барометр, ул икейөзлелекне, ялганны, әйткән сүздә тормауны гафу итә алмый. Минем төп эш принцыбым – һәр баланың ышанычын яулау һәм шул ышанычны эшем белән аклау булды. Тәрбияләү эштә, укуда, бергә аралашуда, кешеләргә булышуда көндәлек тормышта ул.

Балаларны яратканга әбиемне 2004 елда Дусым авылындагы «Кояшкай» балалар бакчасына мөдир итеп билгелиләр. Ул Дусым балалар бакчасында эшен яратып, намус белән башкара Без әбием белән бер гаиләдә яшибез. Ул безгә үзенең яхшы киңәшләрен бирә, әдәплелеккә, тәртипкә өйрәтә. Һәр вакыйганы үз күзлегеннән чыгып бәяли, сөйләшүне уен- көлке белән баета, тапкырлыгына исен китәрлек. Уларын тәртипле итеп тәрбияләгән. Инде безне - оныкларын кайгырта, ярата. Кешеләрне һәм хезмәтне яратыгыз дия.

*Шигапов Гадел **, 8 сыйныф***

### Рәхмәт ишетү –рәхәт!



Мәктәбебезнең 8 сыйныф егетләре һәр эштә алда баралар. Хоккей ярышлары дисеңме, футбол, волейбол уйнарга кирәкме алар сынатмыйлар. Өлкәннәргә булышырга да вакытлары кала. Куәм авылында яшәүче Рәшидә апа аларга рәхмәтләрен әйтеп бетерә алмый. Егетләр йорт тирәсен, капка алларын кардан арчыдылар. Рәхмәт , укучылар, изге эшләрегез дәвамлы булсын.

Тапкырлар тапмый калмас . Ребус чишәбез.



## Минем яраткан уеным.

Һәрбер кешенең яраткан уены була. Ә минем кыш көне яраткан уеным чаңгыда шуу һәм хоккей. Мин кечкенәдән бирле хоккей белән кызыксынам. Әтием дә хоккей уйнарга ярата. Минем әти белән Арча боз сараена да барып шөгыльләнгәнем булды.



Безнең мәктәп янында боз мәйданчыгы бар. Аны зур абыйлар һәм физкультура укытучысы Зарипов Булат абый су белән катырдылар, тигезләделәр, буядылар. Мин аларга бик рәхмәтле. Без мәктәптән кайту белән тимераякларыбызны алып шул шугалакка китәбез. Минем дусларым да килә.Бергәләшеп хоккей уйныйбыз. Хәтта тимераякта шуып тирләп, киемнәребез юешләнеп беткәнен дә сизмибез.Киемнәр бозланып катса да, бияләйдән су тамып торса да, кайтасы килми. Шугалакта бик күңелле, боз шома тип тигез.Шулай булса да мин укырга да, әти-әниемә булышырга да вакыт табам. Спорт безне тәртипкә, вакытны дөрес бүлергә дә өйрәтә.Спорт сәламәтлекне сакларга, үзеңне яхшы хис итәргә ярдәм итә.

Шакиров Раяз, 4 сыйныф

Урамда ай-ай салкын икән,
Агачларның ялы киткән.
Ә үләннәр ак кар астында,
Тыныч йокыга киткән.

*Назмиев Рияз, 4 класс*



## Бәйрәм – тамаша.

Резеда апа: " Әтнә татар дәүләт драма театрына спектакль карарга барабыз",- дигәч, без классыбыз белән бик шатландык. Спектакль буласы көнне түземсезләнеп көтеп алдык.

Театр бинасы бәйрәмчә бизәлгән иде. Фойе уртасында зур яшел чыршы тора. Без аның матурлыгына, андагы уенчыкларга карап сокландык. Чыршы тирәсендә фотога төштек.

Менә залга да уздык. Сәхнәдә "Shurale Trip" спектакле башланып китте. Сәхнә түрендә Кыш бабай һәм Былтыр күренде.

Һәркемнең дә туган көне булган кебек, Кыш бабайның да туган көне була икән. Кыш бабайның туган көнен котлап, Тукай әсәрләренең геройлары Куян, Кәҗә белән Сарык, Шүрәле, Су анасы, Пушкинның Патша кызы, Кызыл калфак һәм башкалар килде.

Тамаша мавыктыргыч, эчтәлекле, күңелле булды. Әкият геройлары кешеләрнең батырлыгына, тугрылыгына, тырышлыгына, дуслыгына ишарәләде.

Без спектакльдән соң күтәренке кәеф белән таралыштык. Ә урамда бөтерелеп ап-ак кар ява иде.

Мин әйтеп бетергесез хисләр, уй-кичерешләр, эмоцияләр алып кайттым.

*Шигапов Ранил, 2 сыйныф*



## Биш бөртек беренчеләр.

Мәктәп бусагасын күптән түгел генә атлап кергән беренче сыйныф укучылары алфавиттагы хәрефләрне өйрәнеп беттеләр. Матур итеп язарга, укырга, сөйләргә аларны укытучылары Люция Фәесхан кызы өйрәтә. Беренчеләр язган шигырьләрне сезгә дә тәкъдим итәбез.



**Без**

Бик әз генә булсак та,
Бердәм һәм бик тату без!
Беренче класс булсак та,
Бик тырышып укыйбыз.

*Хәкимов Риназ,1сыйныф*

**Үзем укыйм**

Нәни чагымда китапны
Әнием укый иде.
Биш яшемнән хәреф ятлап,
Мин үзем укыйм инде.

*Халитова Иркә, 1сыйныф*

## Зур елкада кунакта

Кыш житүгә һәр бала яңа ел бәйрәмен көтеп ала. Безнең районда ел саен укуда, спортта, сәнгатьтә алдынгы балалар өчен чыршы бәйрәме уткәрелә. Мин ул бәйрәмдә быел икенче елымны катнаштым. Бәйрәм буласы көнне иртә белән матур күлмәгемне киеп, бәйрәмгә киттем. Чыршы бәйрәмен Әтнә районы башкарма комитеты житәкчесе Каюмов Айрат Фәнил улы башлап жибәрде. Ул безне бәйрәм белән котлады, киләчәктә уңышлар теләде. Чыршы бәйрәмен Әтнә татар дәүләт драма театры артислары сәхнәләштергән, Г.Минкинаның «Shurale Trip» әкияте дәвам итте. Әкияттә татар Кыш бабае үзенең туган көнен уздырырга әзерләнә һәм моның өчен әкият геройларын үзенең биләмәсе – Кырлайга чакыра.Туган көнгә кунаклар жыю вазыйфасы – Шүрәле һәм Былтырга төшә. Бу сәяхәт аларга күп ачышлар әзерли. Алар чын дуслыкның нәрсә икәнен аңлыйлар. Әкияттә миңа иң ошаган герой - Шүрәле. Аның биюе, жырлары бик матур иде. Әкият геройларының костюмнары искиткеч матур.



Әкият тәмамланганнан соң, Кыш бабай безгә үзенең бүләкләрен тапшырды. Миңа аеруча, бүләкләр арасындагы котлау сүзләре язылган, открытка ошады.

Чыршы бәйрәме бик күңелле узды, киләчәктә ярышларда актив катнашу өчен этәргеч булды.

*Галявиева Алия ,3 сыйныф*

## Минем күрше малае

Безнең күршедә генә бер малай яши. Әни : "И, бигрәк әдәпле инде безнең күрше малае Салават!", -ди. Мин дә аны әдәпле дип уйлыйм. Ул һәрвакыт елмаеп сөйләшә, беренче булып исәнләшә. Зурлар белән бик хөрмәтләп сөйләшә . Һәр көн әнисенә булыша. Мәктәптә дә яхшы укый, гел "4-5" ләләр генә алып кайта. Без аның белән бик дус. Аның белән уйнавы, сөйләшүе бик рәхәт һәм күңелле. Ул беркайчан тупас сүзләр әйтми. Салават кебек инсафлы, әдәпле балалар күбрәк булсын иде.

*Шигапов Камил, 5 сыйныф*

***Сәламәт булып үсәм.***

Жәен, көзен һәм язын
Йөгерәбез ,мин - өлгер.
Уйныйм дисәң
Волейбол, футбол,
Житезлек бик кирәк ул.
Кыш житүгә бергәләшеп,
Чаңгы, чана шуабыз.
Сәламәт яшәү рәвешен
Үтәргә тырышабыз.
Шугалак үзебезнең
Мәктәп янында гына.
Кич белән бала- чага
Кәшәкә тотып чаба.

Хоккейны бик яратам,
Карарга, уйнарга да
Мәктәп командасында уйнап,
Жиңүләр яуларга да.
Сәламәтлек төшенчәсен
Һәркем аңлый үзенчә.
Минем өчен сәламәтлек –
Дөрес яши белүдә.

*Ахмадуллин Ильяр, 9 сыйныф*

**Яңалыклар**

- Татар эстрадасының күренекле жырчысы Әлфия Авзал кызы Авзалованың 13 январьда туган коне. Исән булса аңа 90 яшь тулган булыр иде.
- Шагыйрь, драматург Илдар Гафур улы Юзеевның тууына 90 ел (1933–2004)
- Балалар язучысы, шагыйрь Хәкимҗан Шәяхмәт улы Халиковның тууына 90 ел (1933–2002)
- Балалар язучысы Әминә Әхмәт кызы Бикчәнтәеваның тууына 110 ел (1913–1986) .
- Татар мәгърифәтчесе, фәлсәфәчесе Ш.Мәрҗани тууына 205 ел (1818-1889)



**Январь аенда хөрмәтле укытучыларыбыз Булат Абдулла улы, Люция Фәесхан кызы , Сания Фәрит кызы, Алия Абдулла кызы, пешекчебез Айгөл Илхам кызының туган көннәре. Аларга зур уңышлар, сәламәтлек, гаилә бәхете, тынычлык телибез!**